КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 25 июнь

г.Казань

№ 466

Зеленодольск муниципаль районы акваториясендә «SVIYAGA FEST - 2024» гаилә фестивален уздырганда су объектларыннан файдалану турында

Россия Федерациясе Су кодексының 6 һәм 25 статьялары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләр тормышын саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2009 ел, 23 апрель, 256 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләр тормышын саклау кагыйдәләренең 1.3 пункты нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы акваториясендә «SVIYAGA FEST – 2024» гаилә фестивален үткәргәндә кешеләр тормышы иминлеген тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Аз үлчәмле судноларны, шулай ук җилкәнле, йөреп кайту, спорт судноларын, гидроциклларны, байдаркаларны, ишү көймәләрен дә кертеп, Зөя елгасы һәм Идел тирәли «SVIYAGA FEST - 2024» гаилә фестивален уздыру чорында, ярлардан 600 метр ераклыкта, Зеленодольск муниципаль районы акваториясендә 2024 елның 7 июлендә 8.30 сәгатьтән 14.00 сәгатькә кадәр куллануны тыю (алга таба - тыю) билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына халыкка кертелә торган тыю турында, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чаралары аша мәгълүмат җиткерү эшен оештырырга.

3. Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсенә тыюны үтәү максатларында көчләрнең һәм чараларның кизү торуны тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

4. Тыю «SVIYAGA FEST - 2024» гаилә фестивален әзерләү һәм уздыру өчен җәлеп ителгән судноларга кагылмый дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин